ВӘГАЗЬ
Иң хәерле мирас — тәрбия
→ 4–5 БИТЛӘР

ВАКЫЙГА
Кукмара мәдрәсәсе юбилеен билгеле
→ 6 БИТ

ӘХЛАК
Исламда кунакны каршы алу
→ 7 БИТ

ТАРИХ
«Шамил» мәдрәсәсе — мәхәллә горурлыгы
→ 10–11 БИТЛӘР

**ДЕКАБРЬ, 2023**
№ 12 (341)

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте басмасы

ҖӨМӘДӘЛ-ӘҮВӘЛ–ҖӨМӘДӘЛ-АХЫР, 1445

# دين و معيشت

# ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

12+



Фотоның авторы: 2ikononova / elements.envato.com

**21нче декабрьдә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Пленумы үтте. Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендәге утырыш эшендә аның урынбасарлары, казыйлар, шулай ук бөтен республикадан имам-мөхтәсибләр, аларның ярдәмчеләре һәм мөфтият эшчәнлегенең барлык юнәлешләре һәм оешмалары җитәкчеләре катнашты...**

ДӘВАМЫ → 3нче БИТТӘ

ГАЗЕТАДА АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘНЕҢ ИСЕМНӘРЕ, КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ БУЛГАНЛЫКТАН, БАСМАГА ИГЪТИБАРЛЫ БУЛЫГЫЗ!

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 12 (341) декабрь, 2023 | Җөмәдәл-әүвәл–Җөмәдәл-ахыр, 1445

# Нәзарәттә Коръәннең кулъязма мөсхәфен әзерләү комиссиясе утырышы узды




Фотоның авторы: Илнур Мифтахов/dumrt.ru

**Җөмәдәл-ахыр аеның 1нче көнендә (14нче декабрьдә) Татарстан мөфтияте бинасында Коръәннең кулъязма мөсхәфен әзерләү комиссиясе утырышы үткәрелде.**

Җыелышта катнашу өчен Казанга Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин чакыруы белән Дубайдан дөньякүләм танылган мөселман галиме, дин әһеле, Изге Коръән Дубай халыкара премиясе (DIHQA) Коръән әзерләү комиссиясе башлыгы, хафизлыкның иң югары дәрәҗәсенә ия булган, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең нәсел дәвамчысы, шәех Мәэмүн әр-Рави килде.

Шәех Комиссия составында 2021 елның декабреннән, ягъни проектны тормышка ашыра башлаганнан бирле эшли. Ике ел дәвамында ул кулъязма мөсхәф язуны тикшерүдә читтән торып һәм үзе килеп катнашты. Бүген мөсхәфне әзерләү комиссиясенең чираттагы утырышы узды. Комиссияне Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкли.

Шәех Мәэмүн әр-Рави, утырышта чыгыш ясап, болай диде: «Беренчедән, бу мөсхәфнең уникальлеге — ул нәкъ менә шушы юнәлеш буенча 11 чыганакка таянып языла, һәм башка бик күп мөсхәфләр һәм Коръән басмалары кулланыла. Казан мөсхәфе барысы белән чагыштырыла. ИншәАллаһ, әгәр барысы да яхшы барса, тәмамлыйбыз һәм бу мөсхәф эталон мөсхәф булачак, ягъни аннан чыгып мөсхәфләр язачаклар».

Кулъязма мөсхәф әзерләү проектының төп башкаручысы булып, Казан каллиграфы Артур Писаренко тора. Ул танылган хаттат, Россия Ислам институты каршындагы «Ән-Намир әл-Мухаттат» гарәп каллиграфиясе һәм Ислам сәнгате үзәгенә нигез салучы һәм аның директоры Рамил Насыйбулловның шәкерте. Әлеге эшкә шулай ук Татарстан мөфтиятенең Голәмәләр шурасы гыйльми сәркатибе Рөстәм Нургалиев, Казанның Коръән хафизлар әзерләү үзәге директоры Габдерәшит Фәизов, Нәзарәтнең шәригать мәсьәләләре буенча бүлек белгечләре, мөфти урынбасары, «Хозур» нәшрият йорты җитәкчесе Ришат Хәмидуллин һәм башкалар җәлеп ителде.

Бүгенге көндә Казан кулъязма мөсхәфенең 320 бите (16 җүз) язылган, бу гомуми текстның яртысы дигән сүз.

Проект илебезнең Коръәнне өйрәнү гыйлеме һәм Ислам дин гыйлеме фикере өчен югары фәнни кыйммәткә ия булачак. Моннан тыш, ул — каллиграфия сәнгате әсәре булу белән бергә, әһәмиятле һәм Гыйльмел-Хат Ислам фәнендә югалган татар традицияләрен торгызуда беренче адым. Мөсхәфне язу — Татарстан мөфтиятенең Коръәнгә хезмәт итүдә эзлекле эшчәнлегенең кульминацион этабы буларак та кабул ителәчәк. Әлеге эшнең нәтиҗәсе булып, җирле фәнни-гыйльми берләшмә күзәтчелегендә җирле хаттат тарафыннан кулдан язылган мөсхәф торачак һәм ул басма тираж белән дөнья күрәчәк.

Гыйльмел-Хат — гарәп хәрефләренең язу кагыйдәләрен өйрәнүче фән. Һәрбер хәрефнең үзенең кануни рәвештә билгеләнгән, ләкин шрифт — хаттка карап төрле язылышы бар. Хаттның бер стиле кысаларында бер хәрефнең 100гә кадәр язылыш төрләре кулланыла ала. Хәрефләрнең кагыйдәләр буенча язылмавы хата санала.

Шунысы игътибарга лаек, кулъязма мөсхәфләр әзерләү тәҗрибәсе хәзерге вакытта Согуд Гарәбстаны, Төркия, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Бәһрәйн, Күвәйт, Катар, Ливия, Марокко һәм Пакстанда бар. Хәзер бу эшкә Казанда да керештеләр. Моның өчен шәех Мәэмүн әр-Рави Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең мөсхәф әзерләү комиссиясе киңәшмәсендә катнашты һәм бу эш өстендә шөгыльләнүчеләргә аны төзү һәм язу методологиясен аңлатты.

**dumrt.ru сайтыннан алынды**

# Питрәч мөхтәсибәтенең Беренче Май бистәсендә яңа мәчет ачылды



Фотоның авторы: Илнур Мифтахов / dumrt.ru

**22 нче декабрьдә Питрәч районы Беренче Май бистәсендә «Резеда» мәчете ачылды.**

Әлеге рәсми ачылыш тантанасында Татарстан мөфтиенең мөхтәсибләр белән эшләү буенча урынбасары Равил хәзрәт Зөфәров, Питрәч районы башлыгы Илһам Кашапов, Питрәч районы имам-мөхтәсибе Габбас хәзрәт Шляпошников, эшмәкәрләр, мәхәллә халкы, чакырылган кунаклар катнашты.

Яңа мәчет Питрәч мөхтәсибәте Беренче Май бистәсендә иң матур һәм уңайлы урынында, Үзәк урам, 19А йорт адресы буенча урнашкан. Әлеге җирлектә мәхәллә оештырып, мәчет булдыру артыннан башлап йөрүче шәхесләрнең берсе – авыл аксакалы Илсур Миңневәли улы Аманов була. Мәчет төзелешенә үзеннән зур өлешне Миңнегаян Самат кызы Сәйфетдинова кертә: кызы Резеда вафат булгач, квартирасы барыбер буш тора дип, аны сатып, акчасын мәчет төзелешенә бирә. Хөрмәт йөзеннән авыл халкы мәчеткә «Резеда» мәчете дип исем бирә. Мәчет кыска вакыт аралыгында – нибары бер ел эчендә төзелә, быел 28нче апрельдә ай куела.

Җыелган халыкны сәламләп, Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин исеменнән тантанада катнашучыларга нәсыйхәт сүзләрен аның урынбасары Равил хәзрәт Зөфәров ирештерде.

Рәсми ачылыштан соң, барлык җыелган халык яңа мәчеткә узды, Равил хәзрәт җомга намазын алып барды. Намаздан соң яңа мәчеттә Питрәч мөхтәсибәте имамнары җыелышы үткәрелде.

Мәчет кирпечтән салынган, ике катлы, 200 кешене сыйдыра. Бүгенге көндә барлык төзелеш эшләре тәгәлләнгән, су, газ һәм электр кертелгән.

Мәчеткә имам-хатыйп итеп Илшат хәзрәт Сәлахов билгеләнде.

Бүгенге көндә Питрәч мөхтәсибәтендә барлыгы 24 мәчет эшли.

**dumrt.ru сайтыннан алынды**

# Нәзарәттә «Хашият бине Габидин» буенча лекцияләр узды

**Бу көннәрдә Татарстан мөфтияте бинасында хәнәфи мәзһәбенең Ислам хокукы буенча иң абруйлы фундаменталь хезмәтләреннән саналган «Радд-әл-мухтәр галә Дүрр-үл-Мүхтәр» китабы буенча лекцияләр уза, әлеге басма шулай ук «Хашият бине Габидин» исеме белән дә билгеле.**

Җөмәдәл-ахыр аеның 3нче көнендә (16нчы декабрьдә) шәех, шәригать фәннәре докторы, профессор Хусамеддин Мөхәммәд Салих Фарфур әл-Кадирий әл-Хәсәнә әлеге китап буенча беренче дәрес үткәрде. Шәех Димәшкъ-тән килгән, ул «Билад әш-Шам» университетының Ислам үсеше комплексы җитәкчесе; чагыштырма хокук белеме, заманча фикер, цивилизацияләр һәм диннәр арасында диалог профессоры; Сүриянең Дин (вакыфлар) һәм мәгариф министры консультанты.

Сүрия шәехе лекция укый торган күптомлы «Хашият бине Габидин» хезмәтенең авторы — XIX гасыр галиме, күренекле дин әһеле, 46 фәнни хезмәт авторы Ибне Габидин әл-Хәнәфи. Фундаменталь китап фикһның (Ислам хокукы) барлык бүлекләре буенча фәтвалар — дини карарлар җыентыгы булып тора. Аның эчтәлеге белән Нәзарәтнең «Даруль ифта» бушлай электрон китапханәсендә танышырга мөмкин.

Исегезгә төшерәбез, быелның язында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин рәислегендәге эшче төркем хәнәфи мәзһәбендә иң абруйлы китапларның берсе, Ислам хокукы буенча фундаменталь фәнни әсәр — «Радд-әл-мүхтәр галә Дүрр-үл-Мүхтәр»не гарәп, рус һәм татар телләрендә заманча кыскартылган версиясен әзерләүгә кереште.

Нәзарәт белгечләренә шушы әсәрдә урын алган берничә мең фәтвалар арасында кануни яктан иң дөрес һәм көчле расланган, бүгенге көндә иң актуаль карарларны сайлап алырга туры киләчәк. Эшнең киләсе этабында хезмәт рус һәм татар телләренә тәрҗемә ителәчәк.

Шәех, шәригать фәннәре докторы, профессор Хусамеддин Мөхәммәд Салих Фарфур Диния нәзарәте Пленумы көннәрендә имам-мөхтәсибләр өчен лекцияләр укыячак.

**dumrt.ru сайтыннан алынды**

# ИҢ ХӘЕРЛЕ МИРАС — ТӘРБИЯ

**Тормышның һәр чоры безгә баскычны хәтерләтә: төшәргә дә, күтәрелергә дә туры килә. «Аллаһыга шөкер, уңышка, дәрәҗәгә ирештек», – дип сөенәсең, хәтта горурланасың. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә бу уңышны, дәрәҗәне кайдан бирә, ул кайдан килә?**

Аллаһы Раббыбыз Коръәндә әмер бирә, васыять кыла:

***«Без кешегә ата-анасына игелек күрсәтүне әмер иттек. Анасы аны мәшәкать белән** [тугыз ай карынында]* ***йөртте һәм аны авырлык белән тудырды. Аны йөртүе һәм** [имчәктән]* ***аеруы – утыз ай. Нәтиҗәдә, ул** [бала яшәп]* ***куәтле чагына ирешкәч һәм** [шуннан соң]* ***кырык яшенә җиткәч: «Ий, Раббым! Миңа һәм ата-анама биргән** [сансыз]* ***нигъмәтеңә шөкер итүемне, Син разый булган изге гамәлләр эшләвемне миңа күндер. Минем өчен минем** [үземнән соңгы]* ***нәселемне изгеләрдән кыл. Һичшиксез, мин Сиңа тәүбә иттем һәм мин** [гамәлләрен сиңа тапшырган]* ***мөселманнарданмын», – диде».***

*«Әл-Әхкаф / Ком таулары», 46:15*

Сәгыйть бине Мәлик исемле әнисен бик яраткан сәхабә булган. Ул Ислам кабул иткәч, анасы аңа: «Син Исламнан чыкмыйча торып, мин ашамыйм-эчмим, юынмыйм», – дип шарт куйган, нәзер әйткән. Сәгыйть аңа катырак итеп: «Син теләсә нишлә, мин Исламнан чыкмыйм», – дип кырысрак җавап кайтарган. Шуннан соң Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә «Локман» сүрәсеннән аять иңдерә:

***«Әмма ул икәү** [үзләре турында]* ***синең берниндиɡ гыйлемең булмаган** [потлар һәм гаҗиз]* ***нәрсәләрне** [күрә торып]* ***Миңа ширек кылуың өчен сине көчли калсалар, аларга итагать итмә. Әмма дөньяда ул икәү белән** [дини һәм кешелек ягыннан]* ***яхшы күрелгән рәвештә бергә бул. Ләкин син** [ата-анаңның юлына түгел, тәүхид һәм ихлас белән]* ***Миңа юнәлгәннәрнең юлына ияр...»***

*«Локман», 31:15*

Галимнәр аңлатуынча, ата-ананы рәнҗетә, күңеленә тия торган юл белән түгел, ә йомшаклык белән аларга хөрмәт кыласың, шул ук вакытта тыңламыйсың да. Безнең өчен олы үрнәк — ул Ибраһим галәйһиссәлам. Әлеге пәйгамбәр турында, аның потларга табынучы атасына нинди мәрхәмәтле булуын Аллаһы Тәгалә Коръәндә дә искәртеп үтә.

Раббыбыз ананың атага караганда аерылып тора торган ролен күрсәтеп, болай диде:

***«...Анасы аны зәгыйфьлек өстенә зәгыйфьлек белән йөрткән** [бу көчсезлек чоры авырга узуы белән башланып, нифасы беткәнче дәвам итә]**. Аны имүдән аеруы исә ике ел эчендә.** [Боларның барысы өчен дә, иң элек, Яралтучың буларак]* ***Миңа һәм** [шуннан соң барлыклар арасыннан яралтылыш сәбәбең булган]* ***ата-анаңа шөкер кыл, чөнки кайту – Миңа** [булачак]**».***

*«Локман», 31:14*

Ана кешегә ни өчен игелекле булырга кирәклекне Аллаһы Тәгалә шушы аять аркылы: «Анаң сине күтәргән, имезгән, җанын, җылылыгын биргән чоры утыз айга сузылды», – дип аңлата. Ни өчен Аллаһы Раббыбыз утыз ай: тугыз ай күтәрү һәм ике ел имезү дип әйтте?

Шушы урында хатын-кызның табигатенә, үзенчәлегенә тукталып китик. Коръәндә аерым «Хатыннар» сүрәсе бар, Раббыбыз анда хатыннар хакын кайгыртырга куша. Анда хатыннар темасын күтәргәч, Аллаһы Тәгалә ятим балалар турында әйтә:

***«Ятимнәргә үз малларын бирегез. Пычрак булганын пакь булган белән алмаштырмагыз. Аларның малларын үз малларыгыз белән бергә** [хәләл-харамны кушып]* ***ашамагыз. Һичшиксез, бу** [рәвештә ятим малын ашавыгыз]* ***бик зур гөнаһ булды. Ятимнәргә** [өйләнергә ниятләп, аларга]* ***карата гадел була алмавыгыздан курыксагыз, сезнең өчен хәләл булган хатыннарга – икегә, өчкә һәм дүрткә никахланыгыз...»***

*«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:2-3*

Әлеге хатыннарны алуның төп мәгънәсе – ул бала. Хатын-кыз баланың анасы буларак ягтыртыла.

Хәдискә карасак, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең дүрт кызы булган. Кызы Фатыйма тугач, мөшрикләр: «Синең кызлар, улың юк», – дип хурлап әйткәч, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ул минем рәйхан гөлем, мин аны исним», – дип әйткән. Ул кыз балаларны бик яраткан. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тагын бер хәдисендә: «Кем ике кыз баланы балигъ яшенә кадәр күркәм рәвештә тәрбияли, Кыямәт көнендә ул кеше минем белән бергә булыр», – дигән.

Бервакыт Гайшә радыяллаһу ганһә янына ике кызы белән бер хатын керә. Гайшә анабыз аңа хөрмә бирә, ләкин ул хатын, үзе ашамыйча, шушы ике кызына бүлеп бирә. Гайшә радыяллаһу ганһә бик гаҗәпләнеп, моны Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә сөйли, һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кем кыз бала биреп сынала, аларга күркәмлек кыла икән, бу кыз балалар аңа Кыямәт көнендә уттан пәрдә булырлар», – дип әйткән. Монда кызларның дәрәҗәләре турында әйтелә. Сүз бала турында гына түгел, ә кыз бала турында бара!

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә кыз балаларга аеруча игътибар итә.

Коръәнгә карасак, Аллаһы Тәгалә анда һәрбер нечкәлекләренә кадәр Ислам тарихында булган иң яхшы хатын-кызларның берсе – Мәрьям турында сөйли.

Ибраһим галәйһиссәлам Аллаһы әмере буенча Һаҗәр анабызны бала белән чүл уртасында калдырырга мәҗбүр була. Шул вакытта Аллаһы Тәгалә Исмәгыйльнең аяк астыннан Зәм-Зәм суы чыгара. Һаҗәр анабыз аның пәйгамбәр буласын белгәнме? Юк, белмәгән.

Ә Муса галәйһиссәламнең әнисе Аллаһы Тәгаләнең әмере белән Мусаны сандыкка салып, суга агызып җибәргәндә аның пәйгамбәр икәнен белгәнме? Юк, белмәгән.

Һәр ананың баланы яратуы – бер төрле. Тәҗрибәләр нигезендә шуны гына әйтәләр: хатын-кыз нинди генә чибәр булмасын, аның иң көчле җинаяте – ул бала яратмау. Ә хатын-



Фотоның авторы: Prostock-studio / elements.envato.com

кызның иң көчле, күркәм сыйфаты – ул бала теләү, хатын-кызның бөеклеге – бала ярату.

Татарның бөек шагыйре Габдулла Тукайның анасы Бибимәмдүдә, шагыйрьгә 3 яшь тулгач, вафат була. 3 яшенә кадәр бу балага салган мәгълүмат, җылылык, ярату безнең хәзер «Тукайлы» булуга сәбәпче булган. Тукай гына түгел, имам Әхмәд, имам Әл-Бохари һәм башкалар да шулай ук. Зур-зур галимнәрнең ата-аналары алар бала чакта ук вафат булган, әмма аларны нәкъ тә галим итә торган кешеләр, сәбәпчеләр аларның аналары булган.

Бервакыт тәненең бер ягы гарип булган бала туа, анасы аңа: «Бу гарипллегең белән физик эшләр эшли алмассың, гыйлем юлыннан бар», – дип киңәш бирә. Бу бала олы яшькә җиткәч, Мәккәнең зур галименә әверелә. Ул – Гата бине Әби Рабаһ була. Кем сәбәпле? Ана сәбәпле!

Шушы югарыда әйтелгән аятькә карасак, ананың балага салган мәхәббәте, баланы яратуы 40–50 яшь тулгач ир-атның яки хатын-кызның рухи яктан ныклы шәхес булуына сәбәпче икән.

Кеше өйләнгән вакытта матурлыгына карап кызга өйләнә, әмма беренче баланы алып кайтканнан соң, ул хатын гына түгел, киләчәк буынны тәрбияләүче шәхескә әйләнә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм өчен иң яраткан гамәл – ул никах. Ни өчен? Никах килешүендә сүз хатын белән ирнең бер-берсен яратуы турында гына бармый, ә бу йорттагы киләсе 40–50 ел эчендә формалашачак шәхес турында да сүз бара.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә 20, Әбү Бәкер радыяллаһу ганһегә 18 яшь булганда, алар бергә Шамга сәфәргә баралар. Шушында пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер агач янында туктый да, ял итәргә утыра. Агач янында бер монах була, Әбү Бәкер аның белән сөйләшеп китә. Әбү Бәкер аннан христиан дине турында сораша башлый. Шуннан соң теге монах: «Агач янында кем утыра?» – дип сорый, Әбү Бәкер: «Габделмоталлиб улы Габдулла улы Мөхәммәд», – ди. Тегесе: «Ул – пәйгамбәр! – ди. – Чөнки ул агач янында Гайсә галәйһиссәламнән кала башка кешенең утырганы юк иде, анда пәйгамбәр генә утыра», – дип әйтә. Шуннан соң, 18 яшеннән башлап, Әбү Бәкер Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне калдырмаган.

Ибне Габбас радыяллаһу ганһе әйткән: «Әбү Бәкер – әтисе, әнисе, үзе, хатыны һәм бөтен балалары пәйгамбәребезне күргән, сәхабәләр булган бердәнбер кеше».

Кырык яшенә җиткән кеше уйлап караса, бөтен ирешкән уңышың синеке түгел, ә әниең рухият салган, әтиең юнәлеш, тәрбия биргәннең нәтиҗәсе икәнен аңлый.

Әниләрне тыңлау, аларның хәлен белү әнигә түгел, балага кирәк! Безне күтәргән, тапкан, тәрбияләгән вакытта булган барлык авырлыкларны без белмибез, шуңа күрә: «Раббым, Сиңа шөкер итәргә ярдәм бир миңа, киләчәктә Син миннән риза булырлык итеп яшәргә, гамәл кылырга ярдәм бир миңа, гаиләмне, нәселемне төзек, сәҗдә әһеле кыл», – дип сорыйбыз.

Аллаһы Тәгалә һәркайсыбызга да безнең шәхес булып формалашуыбызда олы хезмәт куйган әти-әниләребезгә игелек кылырга насыйп әйләсә иде. Кечкенәдән алып, авыр вакытларыбызда безне тәрбияләгән, кеше иткән әти-әниләребезгә миһербанлы булсак иде. Аллаһы Раббыбыз безгә әти-әниләрнең кадерен белеп, балаларыбызның аналарының кадерен белеп, киләчәктә безнең өчен догада була торган, бездән дә игелеклерәк, бездән дә артыграк сәҗдә әһеле, галимнәр була торган буыннар тәрбияләргә насыйп әйләсен. Әмин.

**Рамил хәзрәт Бикбаев,**
Балтач районының
Үзәк мәчете имамы

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 12 (341) декабрь, 2023 | Җөмәдәл-әүвәл–Җөмәдәл-ахыр, 1445

# КУКМАРА МӘДРӘСӘСЕ ҮЗЕНЕҢ 25 ЕЛЛЫК ЮБИЛЕЕН БИЛГЕЛӘП ҮТТЕ


Фотоның авторы: Илнур Мифтахов / dumrt.ru

**Җөмәдәл-әүвәл аеның 29нчы көнендә (13нче декабрьдә) Кукмара шәһәре Мәдәният йортында Кукмара мәдрәсәсе оешуның 25 еллыгы уңаеннан зурлап тантана үткәрелде. Әлеге чарада төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләр, уку йортын тәмамлаган шәкертләр, мөгаллимнәр, дин әһелләре, район халкы катнашты.**

Урта һөнәри дини уку йортының чирек гасыр дәвамында күркәм нәтиҗәләргә ирешү сөенечен бүлешү кичәсенә Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов килде. Ул барлык катнашучыларга Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинның сәламнәрен ирештерде, район җитәкчелегенә һәм мөхтәсибәткә, шулай ук мәдрәсә коллективына рәхмәт сүзләрен һәм изге теләкләрен җиткерде, мәдрәсәнең киләчәктә дә зурдан-зур уңышларга ирешүен теләде. Мөфти урынбасары Кукмара мәдрәсәсе директоры Ришат Курамшинны Исламны үстерүгә, дини һәм милли кыйммәтләрне саклауга, рухи мирасны өйрәнүгә, мөселман мәгарифен үстерүгә керткән өлеше, дини һәм хәйрия эшчәнлегендәге казанышлары өчен Нәзарәтнең Мәрҗани медале белән бүләкләде, күп еллар дәвамында хезмәт куючы мөгаллимнәргә медальләр һәм рәхмәт хатлары тапшырды. Әлеге тантанада катнашучылар арасында Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, Болгар Ислам академиясе ректоры Фәрхәт Хөснетдинов, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе җитәкчесенең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин, шулай ук Мамадыш, Урыссу мәдрәсәләре җитәкчеләре, Россия Ислам институты, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе вәкилләре бар иде.

Юбилейга багышланган чарада мәдрәсәнең эшли башлавы, уку йорты өчен Үзәк мәчет янәшәсендә бина салыну тарихы искә алынды, мәдрәсәне тәмамлап, дин юлында хезмәт итүче хәзрәтләрнең һәм мөгаллимнәрнең нәсыйхәтләре тыңланды, гыйлем учагы эшчәнлеге, уку йортында оештырыла торган белем бирү һәм тәрбия чараларына нәтиҗәләр ясалды.

Кукмара мәдрәсәсенең чишмә башы узган гасырның туксанынчы елларына барып тоташа: районның Үзәк мәчете ачылуга ук биредә дин сабаклары бирү эшенә тотыналар. 1994–1998 елларда Кукмара Үзәк мәчете каршында якшәмбе мәктәбендә Ислам дине нигезләрен укыту башланып китә. 1998 елдан, Кукмара мәдрәсәсе дини уку йорты буларак рәсми рәвештә теркәлгәч, дәресләр берничә өлешкә бүленгән мәчет залларында үткәрелә, ә 2008 елда исә халык көче белән мәдрәсә өчен заманча өч катлы бина төзелә. 25 ел дәвамында ике меңгә якын шәкерткә гыйлем бирелә. Уку йортын, ачылган көннән башлап, Ришат хәзрәт Курамшин җитәкли.

Башка дини уку йортлары арасында бу мәдрәсә үзенең халыкчан юнәлеше һәм асыл милли йөзе белән аерылып тора. Биредә беренче көннән алып, хәзергәчә белем бирү бары татар телендә алып барыла. Укучылар — Кукмара җирлегеннән тыш, якын-тирә районнардан һәм Киров өлкәсеннән җыела. Алар арасында, башлангыч дини белем алырга теләүчеләр белән беррәттән, авыл мәхәлләләрендә имам, абыстай һәм Ислам дине нигезләре укытучысы булырга теләгән милләттәшләребез дә байтак. Мәдрәсәдә дини һәм дөньяви белемгә ия булган тәҗрибәле остазлар хезмәт итә. Алар арасында урта махсус һөнәри мәдрәсәләр өчен эшләнгән бердәм уку-укыту стандартларын булдыруда катнашкан мөгаллимнәр дә бар. Мәдрәсә укытучылары тарафыннан төзелгән «Башлангыч мәдрәсәдә өйрәнелә торган сүрәләр һәм догалар», «Ислам дине нигезләре», «Тәҗвид» дәреслеге кебек әсбаплар исә республикабыз мәчетләрендә Ислам дине нигезләре курсларында уңышлы файдаланыла.

Уку йортында ел саен төрле мәдәни чаралар, шәкертләр бәйгеләре, викториналар һ.б. үткәрелә. Раббыбыз Аллаһы Тәгалә Кукмара мәдрәсәсе эшенә Үз рәхмәтен һәм бәрәкәтен салып, әле озак еллар дәвамында республикабызның дини мәгариф системасында уңышлы эшләргә насыйп итсен!

**Нияз Сабирҗанов**

# ИСЛАМДА КУНАКНЫ КАРШЫ АЛУ: ГАСЫРЛАР ДӘВАМЫНДА СЫНАЛГАН ГОРЕФ-ГАДӘТ

**Кунакчыллык — Изге Коръәндә һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Сөннәтендә иң хупланган күренеш. Ул гади генә көнкүреш әдәптән барлыкка килә һәм юмартлык, бер-береңә күркәм мөнәсәбәт һәм җәмгыятьтә узара дуслык урнаштыруны күрсәтә.**


Фотоның авторы: HumbaFrame / elements.envato.com

Коръәндә берничә тапкыр, кешеләрне юмартлыкка, яхшылыкка өндәп, кунакчыллыкның мөһимлеге турында искә төшерелә. Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгалә Коръәндә болай ди:

***«Моңа кадәр** [Мәдинә дигән] **йортта яшәгән һәм күңелләренә иманны салган кешеләр үзләренә** [Мәккәдән] **һиҗрәт кылган кешеләрне** [җаннары-тәннәре белән] **сөяләр, аларга** [мөһаҗирләргә] **бирелгән** [ганимәт малы кебек] **нәрсәләрдән бернинди көнләшү хис итмиләр. Үзләрендә ихтыяҗ булса да,** [ашамыйча-ашатып, киенмичә-киендереп] **аларны үзләреннән өстен күрәләр. Кем дә кем нәфесенең комсызлыгыннан саклана** [һәм Аллаһы юлында сарыф итә]**, шулар — уңышка** [һәм котылуга] **ирешүчеләр».***

*«Әл-Хәшр / Җыен», 59:9*

Әлеге аятьтә Мәдинә шәһәрендәге әнсарларның кунакчыл булулары һәм Мәккәдән килгән мөһаҗирләрне үзләренә кертү һәм бар булганнары белән бүлешергә әзер булганнары турында әйтелә.

Коръәндәге «әзер табын»га карасак, ризыкны башкалар белән бергә ашау турында әйтелә. Изге Коръәндә болай диелә:

***«Мәрьям улы Гайсә** [аларның ниятләре изге булганын аңлагач, Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итеп]**: «Ий, Аллаһ! Ий, Раббыбыз! Безгә күктән бер табын иңдер ки,** [ул иңгән көн] **безнең өчен һәм әүвәлгеләребез, һәм соңгыларыбыз өчен бер бәйрәм һәм** [Синең кодрәтең, минем пәйгамбәрлегемә] **Синнән** [килгән] **бер аять** [һәм могҗиза] **булсын һәм Син** [Үз катыңнан аерым бер нигъмәт белән] **безне ризыкландыр.** [Ризыкларны яралтучы һәм алар өчен берни дә сорамаучы Син генә булганга күрә] **Ризык бирүчеләрнең иң яхшысы Син бит», — дип әйтте».***

*«Әл-Маидә / Табын», 5:114*

Аллаһы Тәгалә тарафыннан табынның тылсымлы рәвештә корылуы – Раббыбызның бер галәмәте. Ул өстәл артында бергә утыруның мөһимлеген күрсәтә.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм гомере буена кешеләр өчен кунакчыллык үрнәге булып торды. Аның бер хәдисендә болай диелә: «Кем Аллаһы Тәгаләгә һәм Кыямәт көненә ышанса, үзенең кунагына юмарт булсын» (әл-Бохари).

Расүлебезнең тагын бер хәдисенә карасак, ул болай дип әйткән: «Башкаларны сыйлагыз, кунакчыл булыгыз, һәрвакыт, бигрәк тә сыйлауга кагылганда, кешегә яхшы булсын дип тырышыгыз, шул ук вакытта Аллаһы каршында ихлас булыгыз» (әс-Суютый).

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең якын сәхабәләренең берсе Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе башкалардан кунакчыл булуы белән аерылып торган. Бервакыт Мәдинәгә бер бәдәви килгән һәм ризык сораган. Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе үз йортына алып барып, үзендә дә ризык аз булуга карамастан, шул булган ризыгын аңа тәкъдим иткән. Сәхабәнең бу гамәле әлеге кешене таң калдырган.

Госман бине Гаффан радыяллаһу ганһе — Пәйгамбәребезнең якын сәхабәләренең тагын берсе. Ул шулай ук бик кунакчыл булган. Бервакыт бер ярлы кеше мохтаҗлыгы аркасында аннан ярдәм сорап килгән. Госман радыяллаһу ганһе аны ашатып кына калмый, өенә дә кучтәнәчләр биреп җибәрә.

Мөселман оешмалары, аерым алганда мөселманнар инициативасы белән йортсыз калганнарны йортлы итү, сәяхәтчеләргә ял итү урыны булдыру, бушлай ашату кебек ярдәмнәр дәвам итә.

Кунакчыллык мөселманнарга гына түгел, башка дин вәкилләренә дә кагыла. Конфессияара диалог, төрле инициативалар булу бер-береңне аңлау һәм бердәмлеккә китерә.

Исламда кунакчыллык — ул нинди дә булса кагыйдәләр генә түгел, ә Коръән һәм Сөннәткә нигезләнгән тирәнтен мәгънәдә рухи практика да. Электән килгән әлеге күркәм гадәт хәзер дә мөселманнарны яхшылык эшләргә илһамландырып тора.

18нче декабрьдә мигрантлар көне билгеләп үтелде. Мигрантны да шулай ук «мөһаҗир» дип атарга була. Ул — тегеяки бу сәбәпле үзенең яшәү урынын үзгәртергә мәҗбүр булган кеше. Сәбәпләре төрле булырга мөмкин: күбрәк акча эшләү, яшәү өчен уңайрак булган урын булдыру, туган җирдә булган сугышлар, кысулар һәм башкалар.

Мигрантларның күп өлеше Урта Азиядән булган кардәшләребез икәне беребез өчен дә сер түгел. Беркем дә туган җирен рәхәтлектән ташлап китми. Шул уңайдан, Мәдинә халкы Мәккәдән куенеп килгән әнсарларга ничек ярдәм иткәнен искә төшерик әле. Нәкъ тә Рәсәй мөселманнары аларга дәүләтебез белән якынаерга, адаптация чорын җиңел үтәргә ярдәм итәргә тиешләр.

**Мөхсин Нурулла**

# «Гаилә һәм хәләл яшәү рәвеше елын игълан итәргә тәкъдим итәм»:

## Нәзарәт Пленумында 2023 елга нәтиҗәләр ясалды һәм 2024 елга бурычлар куелды



Фотоның авторы: Илнур Мифтахов/dumrt.ru

**Җөмәдәл-ахыр аеның 8нче көнендә (21нче декабрьдә) Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Пленумы үтте. Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендәге утырыш эшендә аның урынбасарлары, казыйлар, шулай ук бөтен республикадан имам-мөхтәсибләр, аларның ярдәмчеләре һәм мөфтият эшчәнлегенең барлык юнәлешләре һәм оешмалары җитәкчеләре катнашты.**

Көн тәртибендә төп сорау буларак Татарстан мөфтиятенең һәм аның карамагындагы оешмаларның 2023 ел эшчәнлегенә нәтиҗәләр ясалды һәм 2024 елга бурычлар билгеләнде.

2023 елга йомгак ясап, Мөфти Нәзарәт эшчәнлегендә чагылыш тапкан мөһим вакыйгаларны атады: Фәләстыйндәге дин кардәшләребезгә каршы геноцид, Россиядә ислам финансларын эшләтеп җибәрү буенча экспериментның башлануы һәм Татарстанда игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елы.

Камил хәзрәт быелның 1нче сентябреннән Татарстанда, Дагыстанда, Чечняда һәм Башкортостанда ислам банкингын кертү буенча эксперимент гамәлгә керүен искә төшерде. Ул Диния Нәзарәтендә һәм Россия ислам институтында бу эш күп еллар элек башланганлыгын, экспериментка кадәр үк Татарстанда ислам финанслары буенча белгечләр әзерләнүен билгеләп үтте. Мисал өчен, бүгенге көндә Татарстаннан AAOIFI сертификаты булган 8 белгеч эшли. Россиядә алар – барлыгы 11 кеше. AAOIFI – ул Ислам финанс оешмалары бухгалтерлык хисабы һәм аудиты халыкара оешмасы. Белгечләр РИИда әзерләнде, чөнки 2018 елда биредә AAOIFIның рәсми вәкиллеге һәм имтихан алу үзәге эшли башлады. Моңарчы исә, 2008 елда РИИда Россия Ислам Икътисады һәм Финанслар Үзәге эшли башлады.

– Белгечләр РИИда әзерләнсә, Диния Нәзарәтенең Голәмәләр Шурасында алар хезмәт куя. Голәмәләр 7 финанс оешмасы белән берлектә барлыгы 10 хәләл банк продукты эшләп чыгарып, хәзер аларга даими күзәтү, ягъни тышкы аудит алып бара: дөрес сатыламы алар, шәригать шартлары бозылмыймы, харам акчалар белән буталмыймы һ.б. Алдагы елларда 5 банк продукты эшләнгән иде, быел тагын бишесе гамәлгә кертелде. Болар: «Ак барс капитал» каршында Пай инвестиция фонды; «Иджара лизинг» җәмгыяте белән лизинг; Әлмәт шәһәренең 1 нче лицей-интернаты өчен вакф буларак, Хәйрия эндаумент-фонды; дәүләти булмаган пенсия тупланмасы фонды һәм «Ак Барс Банк» белән берлектә ислам факторингы. Җыеп әйткәндә, бездә мөселманнарның нигезле ихтыяҗларын үтәрдәй барлык продуктлар да эшләнде. Моңарчы, ипотека, банк картасы, өлешләп түләү һәм инвестиция мөмкинлекләре тудырылган иде, – дип аңлатты Мөфти.

Үтеп баручы елда мөфтиятнең иң мөһим казанышларыннан Камил хәзрәт үз чыгышында шулай ук Фәләстыйндәге фаҗигале вәзгыятьтән Нәзарәтнең читтә калмаганлыгына да басым ясады: «Бу сугыш бездән ерак барса да, без аны йөрәккә якын алабыз. Ул, билгеле, быел гына башланмады, ә күп еллар дәвам итте: Фәләстыйндагы дин кардәшләребез озак вакыт дәвамында геноцидка тартыла, ләкин быел гына моңа бөтен дөньяның күзе ачылды. Бу вакыйгалар Нәзарәтнең эшчәнлегенә кагылмыйча китә алмады». Бу уңайдан Мөфти имамнарны мәчетләрдә Фәләстыйнны искә алудан туктамаска, халык белән бергә булырга, бергә дога кылырга, ярдәм җыярга, вәгазьләрне андагы вәзгыятькә багышларга чакырды. Ул шулай ук Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фондында бүгенге көндә Газзәдәге дин кардәшләргә ярдәмгә 55 млн сум җыелуын хәбәр итте һәм аларны максатлы һәм гадел рәвештә тотарга кирәклеген ассызыклады: «Ярдәм, һичшиксез, Газзәгә барып ирешергә тиеш!» Мөфти «Зәкят» хәйрия фондына, имам-мөхтәсибләргә, хәзрәтләргә ярдәмнәр туплауда күрсәткән тырышлыклары өчен рәхмәт җиткерде.

Камил хәзрәт Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елы кысаларында

эшләнгән хезмәтләргә дә тукталып, бу өлкәдәге аерым казанышларны билгеләп үтте: китаплар басылу, иҗади бәйгеләр үтү, зурлап Хәтер көне үткәрелү, мөхтәсибәтләрдә сабантуйлар, фестивальләр уздырылу, РИИда татар теле буенча олимпиада оештырылу белән беррәттән, Татарстанда беренче тапкыр Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм аның сәхәбәләренең асыл ядкәрләре күргәзмәсе ачылды, Мисырның Каһирә шәһәрендә мәшһүр татар галиме Муса Бигиев каберенә истәлек билгесе куелды һәм Татарстанда мәдрәсәләр татар телендә укытуга күчерелде.

Үткән елда Нәзарәт Коръән өлкәсендә дә зур эш башкарды. Бу өлкәдә беренче итеп Камил хәзрәт яңартылган «Казан басмасы» мөсхәфен бастырылып чыгуын атады, икенчедән, кулъязма Коръәнне әзерләүнең уңышлы дәвам итүен һәм бу эшнең куелган сроклардан алда баруын искәртте.

Үзенең чыгышында Мөфти хәзрәт җәмгыятьтә динара һәм милләтара татулыкны саклап калу максатында Нәзарәт тарафыннан берничә актуаль мәсьәлә күтәреп чыгарылуны да искә алды. Мисал өчен, хиҗаб киюне тыю, намаз бүлмәләрен һәм мәчетләрне ябу кебек сорауларга карата тәнкыйть белдерелгән иде.

Камил хәзрәт Нәзарәтнең 2024 елда берничә өстенлекле юнәлешкә игътибарны арттыру бурычын да куйды.

Алар арасында ул Ислам финансларын үстерүне, Halal Life style концепциясен үстерүне, гаилә кыйммәтләрен ныгытуны, махсус хәрби операция зонасындагы солдатларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм итүне һәм мигрантлар белән эшләүне атады һәм барлык мөхтәсибләрне һәм Нәзарәтнең оешма җитәкчеләрен шушы өлкәләргә игътибар биреп эшләргә чакырды. Моннан тыш, хәзрәт 2024 елны Нәзарәттә «Гаилә һәм хәләл яшәү рәвеше елы» дип игълан итәргә тәкъдим итте:

– Россиядә Гаилә елы игълан ителде, ә безнең казыйлар гаилә кыйммәтләрен саклауда бик зур эш башкаралар. Шушы эшне көчәйтеп, аңа барлык мөхтәсибләрне һәм имамнарны да җәлеп итәргә кирәк. Шул ук вакытта хәләл яшәү рәвеше мәсьәләсе дә Нәзарәт өчен бик мөһим булып кала бирә. Аны игътибардан чыгарырга ярамый, республикабыз мөселманнар яшәсен өчен иң уңайлы урын булып калырга тиеш. Halal Life style үз эченә бик киң мәгънәне ала: ул – инфраструктураны да, ислам финансларын да, мөселман базары үсешен дә, гаилә һәм әхлак мәсьәләләрен дә күздә тота. Мөселман гаиләсен хәләл акчалар һәм хәләл ризык белән тәэмин итәргә, балаларына тиешле тәрбия бирергә, гаиләсен хәләл яшәү рәвешендә яшәргә өйрәтергә тиеш.

Мөфтинең тәкъдимен Пленум, шул исәптән Баш казый Җәлил хәзрәт Фазлыев та бертавыштан хуплады.

Утырыш барышында шулай ук Мөфтинең мәгариф буенча урынбасары, РИИ һәм КИУ ректоры Рәфикъ хәзрәт Мөхәммәтшин дини уку йортларында кабул итү кампаниясе нәтиҗәләре белән таныштырып узды, бүгенге көндә мөселман мәгариф системасындагы актуаль мәсьәләләргә тукталды, болар – татар телле имамнар әзерләү, кадрлар резервын булдыру, дини уку йортларын финанслау һәм түләүле укуга күчү буенча сораулар. Пленумда 2023 елда тормышка ашырылган эшчәнлек нәтиҗәләре белән шулай ук Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, Голәмәләр шурасы сәркатибе Рөстәм хәзрәт Нургалиев, Мөфтинең мөхтәсибәтләр белән эшләү буенча урынбасары Равил Зөфәров, Диния нәзарәтенең аппарат җитәкчесе Ирек Арсланов, «Зәкят» хәйрия фонды җитәкчесе Булат Мәрданов чыгыш ясады һәм 2024 елга планнар белән уртаклашты.


Фотоның авторы: Илнур Мифтахов/ dumrt.ru


Фотоның авторы: Илнур Мифтахов/ dumrt.ru

**dumrt.ru сайтыннан алынды**

# «ШАМИЛ» МӘДРӘСӘСЕ — МӘХӘЛЛӘ ГОРУРЛЫГЫ

**«Казан Нуры» мәчетенең тарихы чагыштырмача зур түгел. Ул күп кенә Аллаһы йортлары кебек үзенең ишекләрен 1999 елда ача. Бу — совет хакимлеге елларындагы динсезлектән соң ачылган Аллаһы йортларының берсе. Шул ук елларда мәчетнең башкарма органы рәисе Шамил хәзрәт Исхаков һәм мәхәллә кешеләре мәдрәсә бинасын төзү турында кайгырта башлый. Башта алар Казан шәһәре хакимияте башлыгына «Казан Нуры» мәчете янында мәдрәсә бинасы өчен урын бирүне сорап һәм аны килештерү үтенече белән мөрәҗәгать итәләр. Моңа җавап итеп, Казан шәһәре хакимияте башлыгының 2005 елның 13 июлендә «Әмирхан урамында объектны урнаштыру урынын алдан килештерү турында»гы карары да чыга. Аның нигезендә, мәдрәсә төзү өчен 0,216 гектар мәйданда җир кишәрлеге бүлеп бирелә.**

Рөхсәт алынгач, төзелеш эшләре башлана. 2006 елның сентябрь-октябрь айларында мәдрәсә бинасының нигезе салына. Аның белән Валерий Гайсеевич шөгыльләнә. 2007 елның җәендә Шамил хәзрәт Исхаков Мари-Эл Республикасыннан мәдрәсә бинасы өчен агач бура китертүне оештыра. Аны Җ. Н. Сәфәргалиев һәм Н. А. Мостафин алып кайталар. Әмма бура мәдрәсә биләмәсендә бер елга якын ята, нәтиҗәдә бүрәнәләр карала. Шуннан соң Шамил хәзрәт Мари-Элдан балта осталары бригадасын чакыра, алар бүрәнәләрне чистарталар һәм 2008 елның яз-җәй айларында мәдрәсә бинасы диварларын күтәрәләр. 2008–2011 елларда бураның нык утыруы сәбәпле, беренче эш итеп, ниргәләр арасын мүкләү оештырыла, мәчет һәм мәдрәсә өчен аерым канализация үткәрелә, идәнтүшәмнәр түшәлә, тәрәзәләр һәм ишекләр урнаштырыла, бүлмәләр классларга бүленә.

Мәдрәсә бинасын төзүдә Шамил хәзрәт Исхаковның тынгысызлыгы һәм тырышлыгы зур һәм бәяләп бетергесез була. Ул бинаны һәм эчке бүлмәләрне планлаштыру, төзелеш эшләрен контрольдә тоту белән турыдан-туры шөгыльләнә һәм җитәкчелек итә, кайвакыт базардан үз машинасында чыбыклар һәм төзелеш материаллары алып кайта. Алар һәм башкарылган эшләр өчен акчаны Шамил хәзрәт түли.

2011 елның 6 февралендә Шамил хәзрәт бакыйлыкка күчә, шуннан соң мәдрәсәсә төзелешендә аның күп көч куюын искә алып, уку йортына «Шамил» исеме бирергә карар кылына. Шамил аганың эшен улы Камил Исхаков дәвам итә. Башта ул «Казан Нуры» мәчетенең Попечительләр Шурасы рәисе булып тора, ә 2015 елда «Казан Нуры» мәчетенең Мәхәллә Шурасы рәисе итеп сайлана.

Камил Шамил улы Исхаков, әтисенең васыятенә тугры калып, әтисе төзегән мәчет һәм мәдрәсәне үз карамагына ала. Иң беренче эш итеп, мәчетне төзекләндерү эшләрен башлап җибәрә.

Мәдрәсә проекты булдырылганнан соң, бинада төзелеш эшләре җәелдерелә. Эш күләме дә артканнан арта гына бара кебек. Мәдрәсәнең ике ягында монолит тимер-бетон янкормалар төзелә, анда керү ишекләре, санитария төйнәлешләре һәм баскычлар урнаштырыла. Мәдрәсәгә Әмирхан урамы ягыннан төп керү урыны белән фойе төзелә, түбә, электромонтаж һәм санитария-техник монтаж эшләре, бүлмәләрнең эчке эшләре башкарыла, җылылык челтәрләре, суырткычлар җиһазландырыла. Шул ук вакытта, барлык шәһәр төзелеше, янгын сүндерү һәм санитар-эпидемиология нормаларны үтәү, закон таләпләрен исәпкә алу таләп ителә.

2013 елның июленә мәдрәсә бинасының эчке эшләре нигездә тәмамлана, уку йорты биләмәсе төзекләндерелә. Мәдрәсә бинасы уку-тәрбия процессын оештыру өчен әзер була.

### «ШАМИЛ» МӘДРӘСӘСЕНЕҢ ЭШЧӘНЛЕГЕ

Мәдрәсә үз эшчәнлеген аның бинасы төзелеше тәмамланганнан соң, 2013 елның сентябрендә «Динне укыту һәм дини тәрбия курслары» (мәчет каршындагы курслар) юнәлеше буенча башлангыч мөселман дини укыту учреждениесе буларак башлый. Мөселман дини белем бирүнең әлеге баскычы мөселман мәхәлләләре (мәчетләр) каршында оештырыла. Мәдрәсә Ислам турында башлангыч белем бирә. Анда уку елы сентябрьдән майга кадәр дәвам итә. Мәдрәсәдә белем ир-атлар, хатын-кызлар, 2–6 яшьлек балалар, 7–17 яшьлек малайлар, 7–17 яшьлек кызлар төркемнәренә бүлеп бирелә.

Мәдрәсә 2013 елның сентябреннән 2023 елның июненә кадәрге эшчәнлек чорында укучы төркемнәр һәм укучылар санының тотрыклы үсеше күзәтелә, 2020 елның мартында иң югары күрсәткечкә ирешелә, ул чакта укучы төркемнәр саны 124кә, тыңлаучылар саны 1119 кешегә, укытучылар саны 40 кешегә җитә. Әлеге күрсәткечләр коронавирус пандемиясе таралу һәм кешеләрнең үз-үзләрен изоляцияләү зарурлыгы сәбәпле, 2020 елның апрелендә үзгәрешләр кичерә: төркемнәр һәм укучылар саны шактый кими. 2015 елның маеннан хәзергәчә мәдрәсәне якынча 1270тән артык кеше тәмамлый.

### «ШАМИЛ» МӘДРӘСӘСЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ДҮРТ ЮНӘЛЕШТӘ АЛЫП БАРЫЛА.

Уку йортында өйрәтү курслары юнәлеше үзәк урынны били. Алар «Ислам һәм гарәп теле нигезләре» (өлкәннәр өчен), «Ислам нигезләре балаларга» (3–16 яшьлек балалар һәм үсмерләр өчен), «Гарәп теле» (өлкәннәр өчен), «Гарәп каллиграфиясе» (өлкәннәр өчен), «Иске имля» (өлкәннәр өчен), «Махраҗ» (гарәп бугаз хәрефләрен һәм сузык авазларын артикуляцияләүгә өйрәтү) (өлкәннәр өчен), «Коръәнне тулысынча укып чыгу (хәтм)» (өлкәннәр өчен), «Мәрхүмне соңгы юлга озату йолалары» (өлкәннәр өчен кыска вакытлы курслар), «Таһарәткә һәм намазга өйрәтү» (өлкәннәр өчен кыска вакытлы курслар).

Икенче юнәлеш: укучыларны татар халык һөнәрләренә җәлеп итү максатында түгәрәкләр оештыру. Шул ук вакытта, кул эшләре күнекмәләрен



Фотолар: «Шамил» мәдрәсәсенең шәхси архивыннан

үзләштерү белән бергә, рухи яктан да камилләшү күз алдында тотыла. Моңа Ислам нигезләре турында белем алу, мөселманнарның үзара аралашуы һәм мәдрәсә мохите аша ирешелә.

Мәдрәсәдә шулай ук төрле чаралар, шул исәптән, конкурслар, викториналар, ярышлар һәм бәйгеләр, экскурсияләр уздырыла. «Шамил» мәдрәсәсендә мөселман бәйрәмнәре, кичәләре һәм истәлекле вакыйгалар белән бәйле Ислам тарихы, татар халкы, татар-мөселман мәдәнияте тарихы, татар мөселман галимнәренең, танылган шәхесләрнең тормышы һәм иҗаты буенча чаралар уза. Шулай ук бәйгеләр, ярышлар һәм күргәзмәләр уздыруга зур әһәмият бирелә.

Уку йортында моннан тыш 5–12 яшьлек балалар өчен җәйге лагерьлар оештырыла.

«Шамил» мәдрәсәсендә үз укытучылары арасында да, Татарстанның мәчет каршындагы курслар укытучы-коллегалары арасында да белемнәрне камилләштерүгә зур игътибар бирелә. 2015–2019 елларда аның нигезендә мәчет каршында укытучылар өчен («Мәчетләр каршындагы курсларда Ислам гакыйдәсен укыту проблемалары»), «Мәчетләр каршындагы курсларда Ислам хокукын (фикһ) укыту проблемалары», «Мәчетләр каршындагы курсларда Ислам тарихын укыту проблемалары», «Мәчетләр каршындагы курсларда әхлак укыту проблемалары», «Мәчетләр каршындагы курсларда Коръән белән бәйле предметларны укыту проблемалары» дигән темаларга биш республика семинары уздырыла. Аларда, шул исәптән «Түгәрәк өстәл» форматында да, Ислам фәннәрен укытуда булган проблемалар яктыртыла, динне укыту һәм тәрбия эшчәнлеге тәҗрибәсе белән уртаклашалар, күргәзмә материаллар һәм уку әсбаплары белән танышалар, ачык дәресләр күрсәтелә.

2021 елның октябреннән «Шамил» мәдрәсәсендә Россия Ислам институтының (Казан шәһәре) Дини оешмалар хезмәткәрләренең һәм уку йортлары укытучыларының квалификациясен күтәрү үзәге тарафыннан, өстәмә һөнәри белем бирү «Дини оешмада дингә өйрәтү һәм дини тәрбия бирү» программасы буенча мәчет каршында белем бирүче укытучылар өчен 60 сәгатьлек курслар үткәрелә.

## «ШАМИЛ» МӘДРӘСӘСЕНЕҢ БЕЛЕМ БИРҮ БАЗАСЫ

Мәдрәсәгә кергәч тә, кешеләрне мәдрәсәнең музей экспозициясе каршылый. Музей экспозициясе «Коръән һәм Сөннәт — Исламның беренчел чыганаклары», «Пәйгамбәрләр — Аллаһының кешеләргә олуг рәхмәте», «Ислам нигезләре», «Татар халкы тарихында һәм мәдәниятендә Ислам», «Идел буе Болгарстанында Ислам», «Казан ханлыгында Ислам», «Татар-мөселманнар Россия империясе составында», «Мөселманнар һәм Совет хакимияте», «Хәзерге Татарстанда Ислам», «Казан Нуры» мәчете һәм «Шамил» мәдрәсәсе» һ.б. темаларга стендлардан һәм төрле экспонатлар куелган 9 витринадан тора. Мәдрәсәдә барлыгы 11 уку бүлмәсе бар, аларда берьюлы 208 кеше белем ала ала.

Мәдрәсәнең беренче катында шулай ук 7 уку кабинеты һәм Ислам китапханәсе урнашкан. Әхмәтһади Максуди исемендәге Ислам хокукы (фикһ), Габденнасыйр Курсави исемендәге Коръәни Кәрим, Ризаэтдин Фәхретдин исемендәге Ислам әхлагы, Әхмәт бине Фадлан исемендәге Ислам тарихы, Мөхлисә Буби исемендәге гарәп теле, Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Ислам гакыйдәсе, Татар-мөселман тарихы һәм мәдәнияте музее кабинетларында килүчеләргә күп кенә мәгълүмат бирелә. Галимҗан Баруди исемендәге Ислам китапханәсе фондында 900 данәгә якын китап тупланган.

Мәдрәсәнең икенче катында намаз залы, уен бүлмәсе, этнографик почмак, шулай ук балалар төркемнәрендә укыту өчен 6 уку сыйныфы урнашкан, шуларның дүртесе кабинет буларак җиһазландырылган. Габдрәхим Утыз Имәни исемендәге Ислам әхлагы, балалар өчен Каюм Насыйри исемендәге татар-мөселман тарихы һәм мәдәнияте кабинет-музее, Батырша исемендәге Ислам тарихы, Зәйнулла ишан Рәсүлев исемендәге Ислам гакыйдәсе кабинетлары һәм «Әбием сандыгы» этнографик почмагы килүчеләрне кызыклы мәгълүматлары белән үзенә җәлеп итә.

Бүгенге көндә мәдрәсәдә, аның мөдире, аның урынбасарлары, методистыннан тыш, 44 мөгаллим-мөгаллимә олы яшьтәгеләргә һәм балаларга белем бирә. Аларның барысы да югары яисә урта профессиональ дөньяви белемле.

**Камил хәзрәт Вәлиуллин,**
«Шамил» мәдрәсәсе мөдире

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 12 (341) декабрь, 2023 | Җөмәдәл-әүвәл–Җөмәдәл-ахыр, 1445

# Әбү Бәкер Сиддыйк радыяллаһу ганһенең фазыйләтләре


Фотоның авторы: ayman-zaid/ elements.envato.com

**Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Әбү Бәкерне дус тоту өммәтемә вәҗибтер». Хәзрәти Гомәр радыяллаһу ганһе бу сүзне Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән ишетеп, Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе туган көнне Аллаһы Тәгалә Гаден җәннәтеннән тәҗәлли нурын төшереп әйтте: «Гыйззәтем һәм бөеклегем белән ант итеп әйтәмен, бүген туган баланы сөймәгән кемсәне Гаден җәннәтенә кертмәмен».**

Хөзәйфә радыяллаһу ганһе сөйләде: «Беркөнне Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә оеп иртә намазын укыдык, намазны укып бетергәч, Пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Әбү Бәкер кайда?» – диде. Әбү Бәкер әйтте: «Мин синең алдыңда, йә, Расүлуллаһ», – дип җавап бирде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Син намазга минем белән килгән идең», – диде. Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе: «Әйе, синең белән килдем һәм әүвәлге сафта идем, ләкин тәһарәтемдә шик булып, тәһарәтләнү өчен мәчеттән чыккач: «Йә Әбү Бәкер!» – дигән тавыш ишеттем, карасам, бер алтын савыт эчендә кардан ак, шикәрдән татлы су, ул савыт өстендә: «Ләә иләһә илләллаһу, Мухәммәдүр-расүлуллаһ Әбү Бәкер Сиддыйк», – дип язылган сөлге тора. Шул савыт белән тәһарәт алдым, сөлге белән йөземне сөрттем, намазга кереп оедым», – диде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Сиңа ул суны китергән Җәбраил, сөлгене куйган Микаил иде. Син чыгып киткәч, әүвәлге рәкәгатьнең кыйраәтен тәмамлагач, Исрафил галәйһиссәлам теземне тотты, син килгәнче рөкүгъ кыла алмадым», – диде. («Нәзһәтүл-мәҗәлис» китабыннан алынды).

Хак Тәгалә һәм Пәйгамбәр галәйһиссәлам Әбү Бәкернең фазыйләтен ун урында зикер итте. Аллаһы Тәгалә:

> ***«Ул аларны, алар аны яраталар»***
>
> *«Мәидә / Аш Ялулыгы», 5:54*

дип Коръәни Кәримдә зикер ителгән, Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмне кяферләр эзәрлекләгәндә, Әбү Бәкер аңа юлдаш һәм дус булды, Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

> ***«Тау тишегендә алар икәү».***
>
> *«Тәүбә», 9:40*

> ***«Мөхәммәд галәйһиссәлам Коръәнне дөреслек белән китерде, вә мөэминнәр Коръәннең һәр сүзен дөресләп иман китерделәр, алар гөнаһтан сакланучы тәкъва кешеләрдер».***
>
> *«Зүмәра / Халык Төркеме», 39:33*

Аллаһы Тәгалә «Сиддыйк» дип кушамат бирде. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Әбү Бәкер минем өммәтемдә шәфкатьлеләрдән». Янә Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләргә әйтте: «Әбү Бәкер изгелектә сездән элек булучы». Чөнки Әбү Бәкер балигъ булган кешедән иң әүвәл Ислам динен кабул итте.

Әүвәл Ислам дине өчен малын сарыф итүче Әбү Бәкер булды, дип әйтәләр. Ул Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә кызын бирде. Әүвәл мәчетне бина кылды. Хак Тәгалә Әбү Бәкер радыяллаһу ганһене ике тарафтан Йосыф галәйһиссәламгә охшашлы кылды, дип әйтәләр: Йосыф галәйһиссәламгә Сиддыйк дигән кебек Әбү Бәкерне дә Сиддыйк кылды. Йосыф галәйһиссәламне Рәййан мөлкенә патша һәм хәлифә кылды. Әбү Бәкер радыяллаһу ганһене дә Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәлифәсе итте. Ике тарафтан пакьлек һәм тәкъвалыкта Яхъя пәйгамбәргә охшатты. Әмма Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе күп вакытта Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә охшаган иде.

Әбү Бәкернең радыяллаһу ганһе кәрамәте будыр: Әбү Бәкер радыяллаһу ганһенең гомере ахырына якынлашкач, васыять итте: «Мин үлгәч, кәфенләп, җеназа укыгач, Рауда мөтаһһәрагә (ягъни Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең каберлегенә) барып: «Сәлам сиңа, йә, Расүлуллаһ, Әбү Бәкерне Раудага куярга рөхсәт булырмы?» – дип сорагыз. Әгәр Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм рөхсәт итсә, аның янына күмегез», – диде. Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе вафат булгач, васыяте буенча сәлам биреп рөхсәт сорадылар. Рауда ачылды: «Хуш, дусны дус янына китерегез, дус дустын сагыныр», – дип тавыш килде.

Әбү Бәкер Сиддыйкның җитмеш ике фазыйләте бар иде, дип сөйлиләр. Ул хасиятләр Бәни Исраил пәйгамбәрләренә дә бирелмәде.

**«Пәйгамбәрләр тарихы»** китабыннан

# Йөрәк белән кылган зикерне фәрештәләр язып куямы?

**Хәдисләрдә килгәнчә, зикерне тавышсыз, эчтән генә әйтү яхшырак икәнен беләбез. Ләкин «Әл-Кәшшәф» китабына карасак, зикерне эчтән яки кычкырып әйтүнең нинди дә булса сәбәпләре булырга мөмкин.**


Фотоның авторы: Queenmoonlite / elements.envato.com

«Мөнзир» китабында болай дип әйтелә: «Аллаһы Тәгаләне кычкырып зикер әйтү рөхсәт ителә. Әгәр дә бу рия яки кешегә күрсәтү ниятеннән эшләнмәсә, киресенчә хуплана да. Андый зикернең бәрәкәте башка ишетүче кешеләргә дә ирешә, һәм Кыямәт көнендә әлеге зикерне әйткән кешегә агачлар, ташлар һәм башка тере җан ияләре шаһитлек китерәчәкләр».

Кайбер шәехләр эчтән зикер әйтүне киңәш итәләр, чөнки бу очракта рия булмаячак. Ә бу, үз чиратында, кешенең ниятеннән тора. Үзенең ниятендә нык торган кешегә зикерне тыныч кына әйтү хәерлерәк.

Ибне Мәсгүт радыяллаһу ганһе бервакыт мәчеткә тавыш белән зикер әйтергә җыелган кешеләрне күрә. Алар «ләә иләәһә илләллааһ» кәлимәсен кабатлыйлар иде. «Мин сезне бидгать ясаучылар дип саныйм», — дип әйткән дә, аларны мәчеттән чыгып китүләрен сораган. Әлеге тыюның сәбәбе булып зикерне кычкырып әйтү түгел, ә мәчеттә үзләрен әдәпсез тотулары булган.

Зикернең яшеренлеге тирә-якка таралган үзенчәлекле бер рух белән тоела. Яшерен зикер тел ярдәмендә түгел, ә йөрәк белән әйтелә. Әлеге зикер әйтеп бетергесез рәхәтлек китерә. Монда югарыда әйтелгән зикер турында сүз бармый. Ул зикер тел белән әйтелә, ләкин эчтән генә.

Тәхлил, ягъни «ләә иләәһә илләллааһ» яки тәсбихны иң яхшысы йөрәк белән генә әйтүме яки йөрәк ярдәмендә тел белән дә әйтергәме? Әлеге мәсьәлә буенча берникадәр каршылыклы фикерләр булды. Беренчеләр зикерне яшерен генә әйтү яхшырак диделәр һәм моңа үзләренең дәлилләрен китерделәр. Башкалары исә зикерне тел һәм йөрәк белән әйтү яхшырак диделәр. Икенче фикер дөресрәк.

Имам ән-Нәвәви рахимәһуллаһи Имам Мөслимнең хәдисләр җыентыгындагы шәрехендә дә шушы вариантка өстенлек бирә.

Әгәр дә мөрид яшерен зикерне чын ихласлык белән әйтә икән, «ләә иләәһә илләллааһ» дигән вакытта аның сулышыннан тәмле хуш ис чыгар. Кайбер бөек кешеләр, ислемай кулланмасалар да, үзләреннән тәмле ис чыгаралар. Мондый очраклар күп булган. Кайвакыт алар сулаган һава якты нур булып чыга торган булган.

Йөрәктән, ягъни яшерен әйтелгән зикерне фәрештәләр язамы яки язмыймы? Әлеге сорау буенча шулай ук төрле фикерләр булган. Кайберәүләр: «Фәрештәләр кәгазьгә яза һәм исләрен теркәп куялар», ә икенчеләре: «Алар яза алмаячаклар», — дигәннәр.

Яшерен, йөрәктән әйтелгән зикерне Аллаһы Тәгаләдән кала беркем дә белә, һәм фәрештәләр дә яза алмаячаклар. Шуңа күрә беренче фикер дөресрәк дип санала.

### ЗИКЕР САВАПЛАРЫ

Аллаһы Тәгаләне искә алу, зикер итү — гамәлләрнең әҗер-савап ягыннан олысыдыр. Зикер — күңелләрнең ялтыравыгы, иманның галәмәте һәм билгесе, монафикълыктан бизү, гыйбадәтнең җелеге һәм максатка ирешүнең ачкычы.

Зикер өчен күңелнең әзер, сернең пакь булуы, яшерен кылу зикернең сөннәтләреннән булыр. Яшерен зикер ачык зикердән җитмеш өлеш артык булыр. Яшерен зикер беленмәс, бәлки, хуш ис белән генә беленер.

### РАСҮЛЕБЕЗГӘ САЛАВАТ ӘЙТҮ САВАБЫ

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салаватны күп әйтү — сөннәт гамәл. Салават әйтү Расүлебезнең шәфәгатен һәм Расүлебез белән җәннәт йортында бергә утыруны вәҗиб итәр.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне телгә алганда салават әйт, яисә күңелеңә төшсә, салават әйт. Салават белән бергә Расүлгә сәлам әйт. Язуда, Расүлебезне телгә алганда, салаватны һәм сәламне яз. Доганың башында, уртасында һәм ахырында Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйт. Ул салават белән бергә пәйгамбәрләр галәйһимуссәламнең башкаларына да салават әйт. Иң элек салаватны хуҗабыз Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә әйт. Расүлебезгә салават әйткәндә аның өй җәмагате һәм сәхабәләрне дә куш.

Төчкергәндә, хайван бугазлаганда һәм гаҗәп эш күргәндә салават әйтмә.

**«Ислам юлы»** китабыннан

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 12 (341) декабрь, 2023 | Җөмәдәл-әүвәл–Җөмәдәл-ахыр, 1445



Фотоның авторы: insidecreativehouse / elements.envato.com

**СОРАУ: Әссәламү галәйкүм! Ниндидер гамәл вакытында кулланылган көчебез, мәсәлән, штанга күтәргәндә, бу гамәлгә тәэсир итми, юкса, Аллаһыдан башка тагын кемдер көч барлыкка китергән булып чыгар иде. Болай уйлау бик куркыныч, ул ширеккә китерергә мөмкин. Моны ничек аңларга соң?**

ЖАВАП: Вә галәйкүм әссәлам! Әлеге мәсьәлә гакыйдә фәненең һәр мөселман белергә тиешле иң катлаулы сораулары рәтендә. Аны аңлау өчен зур тырышлык кирәк.

Мисалга сорауда китерелгән очракны карыйк: штанга күтәрү. Мәктәптәге физика дәресләреннән гәүдәбез көч тәсирендә хәрәкәткә килә икәнен хәтерлибез. Бу очракта кешенең штанганы күтәрә торган мускуллары көче турында сүз бара.

Кешедә көч булганны без кире какмыйбыз. Әлеге көчнең барлыгына нинди дәлил бар? Безнең бу көчне сизүебез — дәлил. Авырлык күтәргән һәр кеше үзендә көч барлыгын һәм мускулларында киеренкелек сизә. Димәк, кешенең көче бар. Ул көч кеше ясаган хәрәкәтнең нәтиҗәсенә тәэсир ясыймы соң?

Мускул көченең табигате нинди? Штанга очрагында 3 вариант мөмкин:

— штанга кешенең көче белән күтәрелә;

— штанга Аллаһының көче һәм Кодрәте белән күтәрелә;

— штанга кеше көченең Аллаһы көче белән кушылуы нәтиҗәсендә күтәрелә.

Әгәр кеше хәрәкәт ясар өчен мөстәкыйль көчкә ия була икән, ул күпмедер дәрәҗәдә Аллаһыга бәйсез булыр иде, һәм дөньяда Аллаһыдан башка тагын ниндидер барлыкка китерүче бар килеп чыгар иде. Моның булуы мөмкин түгел, чөнки Аллаһы Үзе Коръәндә әйтә:

> ***«Сезне дә, сез кылган нәрсәләрне дә Аллаһы яралтты».***
>
> *«Саффәт / Сафта торучылар», 37:96*

Бу — кешеләрнең барлык гамәлләре дә, барлык хәрәкәтләре дә Аллаһы тарафыннан барлыкка китерелүенә ачык дәлил.

Штанга Аллаһының көче һәм Кодрәте белән күтәрелүе Әһле Сөннәт күзлегеннән дөрес. Бу очракта, алда әйтелгәнчә, кеше үзендә көчне тоя, сизә, әмма ул көч хәрәкәтнең нәтиҗәсенә тәэсир итми. Бары Аллаһы кешегә бу көчне сизәргә мөмкинлек биргән, бу хәрәкәт Аллаһының теләге белән генә барлыкка килә.

Ә менә штанга кеше көченең Аллаһы көче белән кушылуы нәтиҗәсендә күтәрелә дигән фикер галимнәр тарафыннан кире кагыла. Имам Акмалетдин әл-Бабирти үзенең «Васыя» исемле хезмәткә шәрехендә болай яза: «Бер хәрәкәтне ике барлыкка китерүче көч тормышка ашыра алмый».

Шулай итеп, мәхлукларның барлык хәрәкәтләре дә Аллаһыдан булуын Коръән аятьләре дә, рациональ дәлилләр дә раслый. Ә кеше бу гамәлне, хәрәкәтне сайлап ала. Ахирәттә бу сайлауның нәтиҗәсе кешегә кире кайтарылачак.

Имам Әбу Җәгъфәр әт-Тәхави үзенең «Гакыйдә» китабында яза: «Сәләт, мәсәлән, тәүфыйкъ, мәхлукларга хас түгел, сәләт ул гамәл вакытында гына барлыкка килә. Ә сәламәтлек, мөмкинлек, осталык гамәлгә кадәр була.

> ***«Аллаһы беркемгә дә көченнән килмәслек нәрсә йөкләми».***
>
> *«Әл-Бәкара / Сыер», 2:286*

Кешеләрнең гамәлләрен Аллаһы барлыкка китергән, ә кеше аларны үзендә булдырган.

Автор әйтүенчә, кешедәге гамәл барлыкка килгәнче булган сәләтне аера белү кирәк. Кешегә йөкләнгән шәригать бурычлары (тәклиф) шушы сәләткә нигезләнгәннәр.

Сәләт (мөмкинлек) — ул (намаз уку һәм ураза тоту өчен) сәламәтлек, (хаҗ кылу яисә зәкәт түләү өчен) байлыгың булу, (теге яки бу гамәлне кылу өчен тиешле) гыйлемең булу. Әгәр кешенең бу гамәлләрне үтәргә мөмкинлеге булмаса, әле гамәл аның өчен мәҗбүри булмый. Аллаһы Тәгалә бу хакта болай ди:

> ***«Юл үтеп аңа*** *[җитәргә]* ***көч тапкан кешеләр Аллаһы өчен*** *[Әл-Харам мәчете булган]* ***Бәйткә хаҗ кылырга тиеш».***
>
> *«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:97*

Ягъни моңа сәләтле булмасалар, бу гамәл аларга мәҗбүри түгел.

Аллаһы безне без сәләтле булмаган гамәлләрне кылырга мәҗбүр итми.

Гамәлне кылу өчен көч бу гамәлне кылган вакытта гына барлыкка килә, аңа кадәр дә түгел, аннан соң да түгел, һәм бу көчне Аллаһы барлыкка китерә.

Ә Аллаһы яхшырак белүче!

**Диния нәзарәтенең «Фәтвалар» бүлеге**

## ДҮШӘМБЕ

**07:00** «Хәерле сәгатьтә» 12+
**07:55** «Минбар» 12+
**08:20,17:00** «Онлайн мәдрәсә» 12+
**08:40,17:30** «Бер мәчет тарихы» 12+
**08:55,17:45** «1001 хәзинә» 12+
**09:10,18:00** «Тәфсир». Тимергали Юлдашев 12+
**09:35,18:25** «Фикер» 16+
**10:20,19:15** «Бер хәдис – бер җавап» 12+
**10:45,19:40** «Коръән могҗизалары» 12+
**11:00,19:55** «Дин турында» 12+
**11:30,20:30** «Хикмәтле хикәяләр» 12+
**11:40,20:40** «Намазга өйрәник» (хатын-кызлар өчен) 12+
**12:00** Азан 12+
**12:05,21:00** Мультфильмы 6+
**12:20,21:15** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым» 12+
**12:35,21:30** «Онлайн медресе: Тафсир» 12+
**13:10,22:05** «Знамения Корана в свете современной науки» 12+
**13:25,22:20** «Узнаем у имама» 12+
**14:10** «Разговоры о важном» 12+
**14:15,** 23:05 «Алифба» 12+
**14:35** «Есть вопрос – есть хадис» 12+
**15:00,** 23:25 Ислам без стереотипов 12+
**15:20,** 23:45 Почитайка 0+
**15:35** «Тайна» 12+
**15:55** «Халяль-лайфстайл» 12+
**16:15** «Рухуль Байян» 12+
**16:20** «Ислам сегодня» 12+
**00:55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+

## СИШӘМБЕ

**07:00** «Хәерле сәгатьтә» 12+
**07:55** «Минбар» 12+
**08:30,17:25** «Иң гүзәл исемнәр» 12+
**08:45,17:40** «Ислам мәдәниятенең алтын гасыры» 12+
**09:00,17:50** «Рисәлә» 12+
**09:15,18:05** «Миллият сүзлеге» 12+
**09:35,18:25** «Рухел Бәйән» 12+
**09:45,18:35** «Татарлар тарихы» 12+
**10:30,19:25** «Тәмле булсын» 12+
**10:50,19:45** «Имамнан сорыйк» 12+
**11:40,20:40** «Намазга өйрәник» (ир-атлар өчен) 12+
**12:00** Азан 12+
**12:05,21:00** Мультфильмы 6+
**12:20,21:20** Вера в предопределение 12+
**12:30,21:25** «Онлайн медресе: Сира» 12+
**13:05,22:00** «Дети в саду пророчества» 12+
**13:25,22:20** «40 хадисов 40 толкований» 12+
**14:00,22:55** «Узнаем у имама» 12+
**14:45,23:40** «Халид бин Валид» 12+
**15:40** «Познай свою религию» 12+
**16:00** «Ислам сегодня» 12+
**16:40,00:35** «Поучительные истории» 12+
**16:45,00:40** «Хафтияк Шариф» 12+
**17:00** «Мәслихәт» 12+
**20:35** «Гыйбрәтле хикәяләр» 12+
**00:55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+

## ЧӘРШӘМБЕ

**07:00** «Хәерле сәгатьтә» 12+
**07:55** «Минбар» 12+
**08:20,17:00** «Онлайн мәдрәсә» 12+
**08:40** «Бер мәчет тарихы» 12+
**08:55,17:45** «1001 хәзинә» 12+
**09:10,18:00** «Тәфсир». Тимергали Юлдашев 12+
**09:35,18:25** «Бәрәкәтле гаилә» 12+
**10:20,19:15** «Бер хәдис – бер җавап» 12+
**10:45,19:40** «Коръән могҗизалары» 12+
**11:00,19:55** «Дин турында» 12+
**11:30,20:30** «Хикмәтле хикәяләр» 12+
**11:40** «Намазга өйрәник» (хатын-кызлар өчен) 12+
**12:00** Азан 12+
**12:05,21:00** Мультфильмы 6+
**12:15,21:10** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым» 12+
**12:30,21:25** «Онлайн медресе: Таджвид» 12+
**12:55** «40 хадисов 40 толкований» 12+
**13:30,22:05** «Узнаем у имама» 12+
**14:20,21:50** «Знамения Корана в свете современной науки» 12+
**14:35,22:55** «Есть вопрос – есть хадис» 12+
**15:00,23:20** Ислам без стереотипов 12+
**15:20,23:40** Почитайка 0+
**15:35,23:55** «Тайна» 12+
**15:55,00:15** «Голос разума» 12+
**16:30,00:50** «Рухуль Байян» 12+
**16:35** «История ислама в России» 12+
**17:30** «Хаҗ кылырга өйрәник» 12+
**20:40** «Намазга өйрәник» (ир-атлар өчен) 12+
**00:55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+

## ПӘНҖЕШӘМБЕ

**07:00** «Хәерле сәгатьтә» 12+
**07:55** «Минбар» 12+
**08:20,17:00** «Онлайн мәдрәсә» 12+
**08:40,17:30** «Бер мәчет тарихы» 12+
**08:55,17:45** «1001 хәзинә» 12+
**09:10,18:00** «Тәфсир». Тимергали Юлдашев 12+
**09:35,18:25** «Фикер» 16+
**10:20,19:15** «Бер хәдис – бер җавап» 12+
**10:45,19:40** «Коръән могҗизалары» 12+
**11:00,19:55** «Дин турында» 12+
**11:30,20:30** «Хикмәтле хикәяләр» 12+
**11:40,20:40** «Намазга өйрәник» (хатын-кызлар өчен) 12+
**12:00** Азан 12+
**12:05,21:00** Мультфильмы 6+
**12:20,21:15** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым» 12+
**12:35,21:30** «Онлайн медресе: Тафсир» 12+
**13:10,22:05** «Знамения Корана в свете современной науки» 12+
**13:25,22:20** «Узнаем у имама» 12+
**14:10** «Разговоры о важном» 12+
**14:15,** 23:05 «Алифба» 12+
**14:35** «Есть вопрос – есть хадис» 12+
**15:00,** 23:25 Ислам без стереотипов 12+
**15:20,** 23:45 Почитайка 0+
**15:35** «Тайна» 12+
**15:55** «Халяль-лайфстайл» 12+
**16:15** «Рухуль Байян» 12+
**16:20** «Ислам сегодня» 12+
**00:55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+

## ҖОМГА

**07:00** «Хәерле сәгатьтә» 12+
**07:55** «Минбар» 12+
**08:30,17:25** «Иң гүзәл исемнәр» 12+
**08:45,17:40** «Ислам мәдәниятенең алтын гасыры» 12+
**09:00,17:50** «Рисәлә» 12+
**09:15,18:05** «Миллият сүзлеге» 12+
**09:35,18:25** «Рухел Бәйән» 12+
**09:45,18:35** «Татарлар тарихы» 12+
**10:30,19:25** «Тәмле булсын» 12+
**10:50,19:45** «Имамнан сорыйк» 12+
**11:40,20:40** «Намазга өйрәник» (ир-атлар өчен) 12+
**12:00** Азан 12+
**12:05,21:00** Мультфильмы 6+
**12:20,21:20** Вера в предопределение 12+
**12:30,21:25** «Онлайн медресе: Сира» 12+
**13:05,22:00** «Дети в саду пророчества» 12+
**13:25,22:20** «40 хадисов 40 толкований» 12+
**14:00,22:55** «Узнаем у имама» 12+
**14:45,23:40** «Халид бин Валид» 12+
**15:40** «Познай свою религию» 12+
**16:00** «Ислам сегодня» 12+
**16:40,00:35** «Поучительные истории» 12+
**16:45,00:40** «Хафтияк Шариф» 12+
**17:00** «Мәслихәт» 12+
**20:35** «Гыйбрәтле хикәяләр» 12+
**00:55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+

## ШИМБӘ

**07:00** «Хәерле сәгатьтә» 12+
**07:55** «Минбар» 12+
**08:20,17:00** «Онлайн мәдрәсә» 12+
**08:40** «Бер мәчет тарихы» 12+
**08:55,17:45** «1001 хәзинә» 12+
**09:10,18:00** «Тәфсир». Тимергали Юлдашев 12+
**09:35,18:25** «Бәрәкәтле гаилә» 12+
**10:20,19:15** «Бер хәдис – бер җавап» 12+
**10:45,19:40** «Коръән могҗизалары» 12+
**11:00,19:55** «Дин турында» 12+
**11:30,20:30** «Хикмәтле хикәяләр» 12+
**11:40** «Намазга өйрәник» (хатын-кызлар өчен) 12+
**12:00** Азан 12+
**12:05,21:00** Мультфильмы 6+
**12:15,21:10** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым» 12+
**12:30,21:25** «Онлайн медресе: Таджвид» 12+
**12:55** «40 хадисов 40 толкований» 12+
**13:30,22:05** «Узнаем у имама» 12+
**14:20,21:50** «Знамения Корана в свете современной науки» 12+
**14:35,22:55** «Есть вопрос – есть хадис» 12+
**15:00,23:20** Ислам без стереотипов 12+
**15:20,23:40** Почитайка 0+
**15:35,23:55** «Тайна» 12+
**15:55,00:15** «Голос разума» 12+
**16:30,00:50** «Рухуль Байян» 12+
**16:35** «История ислама в России» 12+
**17:30** «Хаҗ кылырга өйрәник» 12+
**20:40** «Намазга өйрәник» (ир-атлар өчен) 12+
**00:55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+

## ЯКШӘМБЕ

**07:00** «Минбар» 12+
**07:35,17:25** «Шифа» 12+
**08:10,18:00** «Фикер» 12+
**09:00,18:50** «Дин турында» 12+
**09:35,19:20** «Мәслихәт» 12+
**10:00,19:45** «Әхлак сабаклары» 12+
**10:10,19:55** «Балам-багалмам» 12+
**10:35** «Имамнан сорыйк» 12+
**11:25** «Намазга өйрәник» ир-атлар өчен 12+
**11:45** «Миллият сүзлеге» 12+
**12:00** Азан 12+
**12:05** «Онлайн медресе: Тафсир» 12+
**12:30,21:25** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым» 12+
**12:45,21:40** «Минбар. Истории» 12+
**13:15,22:10** «Ислам сегодня» 12+
**13:55,22:50** «Познай свою религию» 12+
**14:15,23:10** «Узнаем у имама» 12+
**15:00** Ислам без стереотипов 12+
**15:20** Почитайка 0+
**15:35,00:25** «Медицина Пророка» 12+
**16:00** Короткометражный фильм 12+
**16:25** «40 хадисов 40 толкований» 12+
**17:00** «Онлайн мәдрәсә» 12+
**20:20** «Намазга өйрәник» хатын-кызлар өчен 12+
**20:40** «Тәмле булсын» 12+
**21:00** «Онлайн медресе: Сира» 12+
**23:55** Короткометражный фильм
**00:50** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+


# ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**

Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе **Камил СӘМИГУЛЛИН;**

«Хозур» нәшрият йорты директоры **Ришат ХӘМИДУЛЛИН;**

ТР МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе **Булат МӨБАРӘКОВ;**

Татарстанның баш казые **Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**

ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы **Габдулла ӘДҺӘМОВ**

Баш мөхәррир: **Хамматов Л. Г.**
Мөхәррирләр: **Ситдикова Г. Р., Хәбибрахманова И. И.**
Логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Гарифуллин И. Ф.**
**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:** 420111, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** izdat@huzur.ru

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**НӘШИР:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6нчы йорт).
Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16нчы февралендә 240нчы номер белән теркәлгән.

Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 000 данә. Заказ № 2596.
График буенча – 25нче декабрь, 21.00, гамәлдә – 21.00 сәгатьтә кул куелды.
Газетага ярты елга язылу бәясе – 175,38 сум.
Индексы – П4333. Чыгу көне: 27нче декабрь.
Казан шәһәренең мәчетләрендә 28нче декабрь көнне таратыла.

# НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

## ГЫЙНВАР 2024 / КАЗАН

| Көн | Көн исеме | ИРТӘНГЕ НАМАЗ | | Кояш чыга | ЗӘВӘЛ | ӨЙЛӘ НАМАЗЫ | ИКЕНДЕ НАМАЗЫ | АХШАМ НАМАЗЫ, ИФТАР | ЯСТУ НАМАЗЫ |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | | |
| 01 | Дүш | 05:53 | 06:43 | 08:13 | 11:46 | 12:00 | 13:33 | 15:20 | 17:18 |
| 02 | Сиш | 05:53 | 06:42 | 08:12 | 11:47 | 12:00 | 13:34 | 15:21 | 17:19 |
| 03 | Чәрш | 05:53 | 06:42 | 08:12 | 11:47 | 12:00 | 13:35 | 15:23 | 17:20 |
| 04 | Пәнҗ | 05:52 | 06:42 | 08:12 | 11:48 | 12:00 | 13:36 | 15:24 | 17:21 |
| 05 | Җом | 05:52 | 06:41 | 08:11 | 11:48 | 12:00 | 13:38 | 15:25 | 17:22 |
| 06 | Шим | 05:52 | 06:41 | 08:11 | 11:49 | 12:00 | 13:39 | 15:27 | 17:23 |
| 07 | Якш | 05:52 | 06:40 | 08:10 | 11:49 | 12:00 | 13:40 | 15:28 | 17:24 |
| 08 | Дүш | 05:52 | 06:40 | 08:10 | 11:49 | 12:00 | 13:42 | 15:30 | 17:26 |
| 09 | Сиш | 05:51 | 06:39 | 08:09 | 11:50 | 12:00 | 13:43 | 15:31 | 17:27 |
| 10 | Чәрш | 05:51 | 06:38 | 08:08 | 11:50 | 12:00 | 13:45 | 15:33 | 17:28 |
| 11 | Пәнҗ | 05:50 | 06:37 | 08:07 | 11:51 | 12:00 | 13:46 | 15:34 | 17:29 |
| 12 | Җом | 05:50 | 06:36 | 08:06 | 11:51 | 12:00 | 13:48 | 15:36 | 17:31 |
| 13 | Шим | 05:49 | 06:36 | 08:06 | 11:51 | 12:00 | 13:49 | 15:38 | 17:32 |
| 14 | Якш | 05:49 | 06:35 | 08:05 | 11:52 | 12:00 | 13:51 | 15:40 | 17:34 |
| 15 | Дүш | 05:48 | 06:33 | 08:03 | 11:52 | 12:00 | 13:52 | 15:41 | 17:35 |
| 16 | Сиш | 05:47 | 06:32 | 08:02 | 11:53 | 12:00 | 13:54 | 15:43 | 17:36 |
| 17 | Чәрш | 05:46 | 06:31 | 08:01 | 11:53 | 12:00 | 13:56 | 15:45 | 17:38 |
| 18 | Пәнҗ | 05:46 | 06:30 | 08:00 | 11:53 | 12:00 | 13:58 | 15:47 | 17:39 |
| 19 | Җом | 05:45 | 06:29 | 07:59 | 11:54 | 12:00 | 13:59 | 15:49 | 17:41 |
| 20 | Шим | 05:44 | 06:27 | 07:57 | 11:54 | 12:00 | 14:01 | 15:51 | 17:43 |
| 21 | Якш | 05:43 | 06:26 | 07:56 | 11:54 | 12:00 | 14:03 | 15:53 | 17:44 |
| 22 | Дүш | 05:42 | 06:25 | 07:55 | 11:54 | 12:00 | 14:05 | 15:55 | 17:46 |
| 23 | Сиш | 05:41 | 06:23 | 07:53 | 11:55 | 12:00 | 14:07 | 15:57 | 17:47 |
| 24 | Чәрш | 05:40 | 06:22 | 07:52 | 11:55 | 12:00 | 14:09 | 15:59 | 17:49 |
| 25 | Пәнҗ | 05:39 | 06:20 | 07:50 | 11:55 | 12:00 | 14:10 | 16:01 | 17:51 |
| 26 | Җом | 05:37 | 06:18 | 07:48 | 11:55 | 12:00 | 14:12 | 16:03 | 17:52 |
| 27 | Шим | 05:36 | 06:17 | 07:47 | 11:56 | 12:00 | 14:14 | 16:05 | 17:54 |
| 28 | Якш | 05:35 | 06:15 | 07:45 | 11:56 | 12:00 | 14:16 | 16:07 | 17:56 |
| 29 | Дүш | 05:34 | 06:13 | 07:43 | 11:56 | 12:00 | 14:18 | 16:09 | 17:58 |
| 30 | Сиш | 05:32 | 06:12 | 07:42 | 11:56 | 12:00 | 14:20 | 16:11 | 17:59 |
| 31 | Чәрш | 05:31 | 06:10 | 07:40 | 11:56 | 12:00 | 14:22 | 16:14 | 18:01 |